**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**
**Апак авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Аппаковского сельского поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Апак авылы, Тынычлык урамы,1
тел./факс 8(84346) 76-443

Адрес: 422888, РТ, Алькеевский
район, с. Аппаково, ул.Мира. д.1
тел./факс 8(84346) 76-443

# П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

2018 елның 30 ноябре 26№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Аппак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә 2018 елның 20 ноябрендәге 33 номерлы «Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Аппак авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге гражданнарының кушымтада бирелә торган үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: И. Х. Әбҗәббарова

Аппак авыл җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 30 ноябрендәг
26 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү киләсе календарь елның 1 гыйнварына кадәр җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Аппак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 18 яшькә җитмәгәннәр, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланк гражданнар игътибарына Аппак авылы мәгълүмат стендларында һәм Әлк муниципаль районы http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтыны Аппак авыл җирлеге битендә басылып чыгу һәм халыкка игълан итү юлы шулай ук кәгазьдә имзалатып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллам белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчер реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торга түләү суммасы, түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Аппак авы җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча почта күчерүләрен (исәп хисап оешмалары) башкаруга исәп-хисап ясау хокукына ия оешма аша яис Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аш https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы аша акча күчерү юлы белән башкарыла

6.Түләү фактын касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү факты раслаучы башка документлар раслый.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Аппак авыл җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 30 ноябрендәге
26 номерлы карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ______ №

Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
________________________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүченең Ф.И.О. ________________________________________
Адресы: ________________________________________
Нигездә:________________________________________
Сезгә бер тапкыр түләнә торган түләүне__________________ вакыты җиткәнче түләргә кирәк
__________________________________________ сум күләмендә
реквизитлар :________________________________________
Алучының банкы БИК ______________________________
Сч. № __________________________
Алучы Сч. № ______________________________
ИНН ______________________________
КПП ______________________________
КБК ______________ ОКАТО ____________
Түләү билгеләмәсе
________________________________________________
________________________________________________

Җитәкче ______________ ________________
М.У. (имза) (имзаны җәелдерү)

**кисү линиясе-** - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә № ______________
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
____________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)
суммада ______________ сум.
Түләүче Ф.И.О.
________________________________________________
Адресы: ________________________________________
Алдым 20___ ел. "__" ______________ ________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Киселгән өлеше хәбәрнамә тапшырылса, тутырыла һәм Аппак авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*